| ГЛАВА БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.04.2026 ел Баулы шәһәре №58

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Новозареченск авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар, (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәсе, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 17 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Новозареченск авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты (алга таба - Проект) буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Проект буенча ачык тыңлаулар инициаторы – Баулы муниципаль районы Башлыгы.

3. Ачык тыңлауларны уздыруны 2026 елның 23 апреленнән 2026 елның 11 маена кадәр билгеләргә.

4. Ачык тыңлауларда каралырга тиешле Проект экспозициясен 2026 елның 23 апреленнән ачарга:

4.1. Экспозицияне уздыру урыны:

Татарстан Республикасы Баулы районы Новозареченск авыл җирлеге Башкарма

комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Новозареченск авылы, Вахитов ур., 15 й. адресы буенча;

- Татарстан Республикасы, Баулы районы, Николашкино авылы, Совет урамы, 38а йорт адресы буенча урнашкан бинада;

- Татарстан Республикасы, Баулы районы, Измайлово авылы, Беренче Май ур., 17А адресы буенча урнашкан бинада;

- Татарстан Республикасы, Баулы районы, Дмитриевка авылы, Чапаев ур., 14а адресы буенча урнашкан бинада;

-Татарстан Республикасы, Баулы районы, Таллыкүл авылы, Вахитов ур., 15 й. адресы буенча урнашкан бинада;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә www.bavly.tatarstan.ru Баулы муниципаль районы сайтында.

4.2. Экспозицияне карау режимы:

- Татарстан Республикасы Баулы районы Новозареченск авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Новозареченск авылы, Вахитов ур., 15 й. адресы буенча;

- Татарстан Республикасы, Баулы районы, Николашкино авылы, Совет урамы, 38а йорт адресы буенча урнашкан бинада;

- Татарстан Республикасы, Баулы районы, Измайлово авылы, Беренче Май ур., 17А адресы буенча урнашкан бинада;

- Татарстан Республикасы, Баулы районы, Дмитриевка авылы, Чапаев ур., 14а адресы буенча урнашкан бинада;

-Татарстан Республикасы, Баулы районы, Таллыкүл авылы, Вахитов ур., 15 й. адресы буенча урнашкан бинада;

Эш көннәрендә Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 сәгатькә кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр.

5. Ачык тыңлауларда катнашучылар 2026 елның 23 апреленнән 2026 елның 11 маена кадәр эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- язмача рәвештә ачык тыңлауларны оештыручыга: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт, 101 каб. адресы буенча;

- Bauly.arch@mail.ru электрон почтасы аша.

6. Ачык тыңлауларны оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитетын (алга таба – ачык тыңлауларны оештыручы) билгеләргә.

7. Ачык тыңлауларны оештыручыга:

7.1. Проектны карау буенча ачык тыңлауларны уздыруны тәэмин итәргә;

7.2. Проект буенча ачык тыңлаулар башлану турында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлеге Новозареченск авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» челтәрендәге Баулы муниципаль районы  сайтында (www.Bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга;

7.3. Экспозицияләрне Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Новозареченск авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында 2026 елның 23 апреленнән 2026 елның 11 маена кадәр эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 сәгатькә кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru оештырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы И.И. Гозәеров